ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

Х. Такташа ул., 94, а/я 44, Казань, 420107

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ, ӘЙЛӘНЕШЕ
ҺӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ
КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН
ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь
инспекциясе)

һ.Такташ урамы, 94 нче йорт, Казан шәһәре, 420107

# БОЕРЫК

19.04.2018 № 12-07/57

Казан ш.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь
инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет
турында

«Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында” 18 ноябрь, 2010 ел, № 906 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

**1.** Расларга (кушымта итеп бирелә):

Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне;

Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе каршындагы Иҗтимагый советны оештыру тәртибен.

2.Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлегенә (Б.Г. Эйдиновка) бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3.Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенең түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

- “Иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында” 22 апрель, 2015 ел, № 12-07/19;

- “Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе каршындагы Иҗтимагый советка үзгәрешләр кертү турында” 7 сентябрь, 2015 ел, № 12-07/57;
- “Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе каршындагы Иҗтимагый советка үзгәрешләр кертү турында” 11 гыйнвар, 2016 ел, № 12-07/1.

**2.** Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **Ж.Й.Әхмәтханов**

Административ һәм суд практикасы
бүлеге
начальнигы урынбасары ________________________________/И.И. Җамалетдинов/_________

Кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы
көрәш бүлеге начальнигы ____________________________/Л.П. Василина/____________

Татарстан Республикасының Этил
спирты, алкогольле продукция

житештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенең
19.04. 2018 ел,
№ 12-07/57 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция житештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет (алга таба – Иҗтимагый совет) Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе) каршындагы, Россия Федерациясе субъектлары карамагына кертелгән вәкаләтләр чикләрендә алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү буенча дәүләт сәясәтен булдыру һәм тормышка ашыруда Россия Федерациясе гражданнарының хокукларын һәм ирекләрен Татарстан Республикасында тормышка ашыруга, шулай ук куллану базарында закон бозуларны кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруга бәйле мәсьәләләрне (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлеге өлкәсе) карап тикшерүне хәл кылучы киңәшмә органы булып тора.

1.2. Иҗтимагый советның составы һәм әгъзалары саны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән раслана.

1.3. Иҗтимагый совет үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) таяна.

1.4. Иҗтимагый совет карарлары – тәкъдим итү характерында.

1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангычта хәл кыла.

1.6. Иҗтимагый советның эше ихтыярый нигездә, хәбәрдарлык һәм партнерлык принципларында һәм Россия Федерациясе,Татарстан Республикасы законнарына катгый төстә туры китереп корыла.

1.7. Иҗтимагый совет үзенең эшен гражданлык җәмгыяте институтлары, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең үзара кызыксынуы нигезендә алып бара.

## 2. Иҗтимагый советның максатлары, бурычлары һәм вәкаләтләре

2.1. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары булып тора:

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыру һәм тормышка ашыруда Россия Федерациясе гражданнарының ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, Россия Федерациясе гражданнарының хокукларын һәм ирекләрен һәм иҗтимагый берләшмәләрнең хокукларын яклау;

иҗтимагый һәм һөнәри берләшмәләр вәкилләрен Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлеге өлкәсенә керүче мәсьәләләр буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләүгә җәлеп итү, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эшчәнлегендә хәбәрдарлык һәм ачыклык принцибын тормышка ашыру;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан күрсәтелә торган дәүләти һәм (муниципаль) хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатына иҗтимагый контрольлекне көчәйтү, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлеге өлкәсендә ачыклык, законлылык, профессионализм принципларын үстерү.

2.2. Иҗтимагый советның бурычлары булып тора:

Россия Федерациясе субъектлары карамагына кертелгән вәкаләтләр чикләрендә, алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә, шулай ук куллану базарында закон бозуларны кисәтү һәм булдырмый калуга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлеге өлкәсендәге мәсьәләләргә кагылышлы норматив-хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрү, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан эшләнелә торган дәүләт программалары проектлары буенча фикер алышулар үткәрү;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең хәбәрдарлыгын үстерү.

2.3. Иҗтимагый советның максатлары һәм бурычлары, эш нәтиҗәләренә бәйле рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасындагы икътисадый, социаль һәм сәяси вәзгыятьтән чыгып, үзгәртелергә һәм аларга өстәмәләр кертелергә мөмкин.

## 3. Иҗтимагый советның составы

3.1. Иҗтимагый совет составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә расланыла торган Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм куллanучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе каршындагы Иҗтимагый советны оештыру тәртибе нигезендә булдырыла.

3.2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе Иҗтимагый совет составы расланылганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча Иҗтимагый советның беренче утырышын үткәрүне оештыра. Анда Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан аның рәисе һәм рәис урынбасары сайлана. Карар, ачык тавыш бирү юлы белән, Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынна күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.3. Иҗтимагый совет рәисен яки рәис урынбасарын вазыйфасыннан азат итү мәсьәләсе Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең мөрәҗәгате буенча, шулай ук Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасарының шәхсән гаризасы буенча яисә Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан кимендә биштән бер өлешен тәшкил иткән санда Иҗтимагый советның бер төркем әгъзалары тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет тарафыннан карала. Карар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.4. Иҗтимагый совет рәисе Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан Иҗтимагый советның җаваплы секретарен билгели.

3.5. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре срогы яңа оештырылган Иҗтимагый совет составының беренче утырышы үткәрелгән көннән башлап өч ел тәшкил итә.

3.6. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре, түбәндәге очракларда, Иҗтимагый совет рәисе танытмасы белән, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе боерыгы нигезендә туктатып торыла:

Россия Федерациясе җинаять-процессуаль законы нигезендә билгеләнгән тәртиптә, аңа җинаять кылуда гаепләү белдерелгәндә;

аңа административ арест рәвешендә административ җәза билгеләнгәндә;

аны дәүләт хакимияте законнар чыгару (вәкиллекле) органына кандидат сыйфатында, җирле үзидарә органында сайланулы вазыйфага кандидат сыйфатында, сәяси партиягә кандидатның ышанычлысы яки вәкаләтле вәкиле сыйфатында теркәгәндә, шулай ук аны Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициативалы төркем составына керткәндә.

3.7. Түбәндәге очракларда Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре туктатыла:

вәкаләтләре срогы чыкканда;

Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза тапшырганда:

сәламәтлеге какшап китү сәбәпле Иҗтимагый совет эшендә катнаша алмаганда;

үзенә карата чыгарылган судның гаепләү хөкеме законлы көченә кергәндә;

законлы көченә кергән суд карары нигезендә аны эшкә сәләтсез яки хәбәрсез каядыр китеп югалган дип таныганда;

әхлак нормаларын тупас бозганда – утырышта катнашкан Иҗтимагый совет әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

Иҗтимагый совет утырышлары эшендә нигезле сәбәпсез системалы төстә (өч тапкырдан күбрәк) катнашмаганда;

Иҗтимагый совет рәисе яки рәисе урынбасары поручениеләрен нигезле сәбәпсез системалы төстә (ике тапкырдан күбрәк) үтәмәгәндә;

аны Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яки муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләгәндә;

чит ил гражданлыгын алганда;

Россия Федерациясе гражданлыгын туктатканда.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктату Иҗтимагый совет әгъзасының язмача гаризасы яки Иҗтимагый совет рәисе яисә рәисе урынбасарының танытмасы нигезендә, шулай ук бу Нигезләмәнең 3.7 пунктында күздә тотылган хәлләр ачыкланган очракта хәл ителә.

Иҗтимагый совет әгъзасы Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына бу Нигезләмәнең 3.7 пунктындагы дүртенче, бишенче, унынчы – уникенче абзацларында күздә тотылган хәлләрнең килеп чыгуы турында хәбәр итәргә тиеш.

## 4. Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасы хокуклы:

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе инициативасы белән үткәрелә торган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, “Түгәрәк өстәл”ләрдә һ.б.) катнашуга, предметы дәүләт сере булып торган мәгълүматлар, персональ мәгълүматлар һәм танышу чикләнгән мәгълүматлар буенча фикер алышу булган чаралардан тыш;

иницатива күрсәтү тәртибендә Иҗтимагый советка аналитик запискалар, докладлар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләп җибәрүгә;

Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышларын үткәрү тәртибенә тәкъдимнәр кертүгә;

көн тәртибендәге мәсьәләләрне карап тикшерүдә катнашу өчен Иҗтимагый совет утырышларына чакырыла торган затларның кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертүгә;

Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыгуга.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы бурычлы:

Иҗтимагый совет рәисе биргән порučениеләрне үтәүгә;

бу Тәртиптә күздә тотылган Иҗтимагый советның эш тәртибен белергә һәм үтәргә;

Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашуга;

Иҗтимагый советка йөкләнгән бурычларны хәл кылу өчен Иҗтимагый совет тарафыннан оештырыла торган экспертлар, эш төркемнәрендә, комиссияләрдә, башка эш органнарында катнашуга.

## 5. Иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Иҗтимагый совет үзенең эшен Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме белән Иҗтимагый совет утырышында расланыла торган планнар һәм программалар нигезендә оештыра.

5.2.Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзаларының, Иҗтимагый совет рәисе һәм Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең тәкъдимнәре нигезендә хәл ителә.

5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5.4. Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашкан очракта, Иҗтимагый совет утырышлары, узды, дип санала. Иҗтимагый совет әгъзасы утырышта шәхсән катнашу мөмкинлегенә ия булмаганда, көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз тавышын һәм фикерен язмача, факсимиль элемтә яки электрон почта аша Иҗтимагый советның башка әгъзасына тапшыруга, бу хакта алдан ук Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына яисә Иҗтимагый советның җаваплы секретаренә хәбәр итеп, хокуклы. Утырышта катнашучы Иҗтимагый совет әгъзаларына үзләренең тавышын Иҗтимагый советның башка әгъзаларына ышанып тапшырган Иҗтимагый совет әгъзалары өстәлә.

Иҗтимагый совет карарлары күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Иҗтимагый совет рәисе яки әгъзалары тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет рәисе белән килештерелгән кайбер мәсьәләләр Иҗтимагый советның барлык әгъзаларына электрон почта аша материаллар җибәрү юлы белән каралырга мөмкин.

5.5.Иҗтимагый совет утырышларын Иҗтимагый совет рәисе, ә ул югында – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары үткәрә.

5.6. Иҗтимагый советның үзенә йөкләнгән максатлары, бурычлары, вәкаләтләре нигезендә кабул ителә торган карарлары – тәкъдим итү характерында.

Иҗтимагый советның үзенә йөкләнгән максатлары, бурычлары, вәкаләтләре нигезендә кабул ителә торган карарлары тәкъдим итү характерында булып, кызыксынулы затлар игътибарына Иҗтимагый советның беркетмәсеннән өземтә рәвешендә яки Иҗтимагый совет карары буенча башка ысул белән җиткерелә.

5.7. Иҗтимагый советның эш материаллары Иҗтимагый советның "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына яки Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе сайтының "Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет" бүлегенә урнаштырыла.

5.8. Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне хәл итә;

Иҗтимагый совет утырышларын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый советның эш планын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны Иҗтимагый советка раслауга тапшыра;

Иҗтимагый совет утырышларын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый советның тәкъдимнәренә, беркетмәләренә һәм Иҗтимагый советның башка документларына кул куя;

Иҗтимагый совет утырышларын үткәрү вакытын һәм урынын билгели;

Иҗтимагый совет эшчәнлеге, аңа йөкләнгән максатлар һәм бурычлар кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына поручениеләр бирә;

Иҗтимагый совет исеменнән запросларга, рекомендацияләргә, тәкъдимнәргә, җавапларга, аңлатмаларга һәм мөрәҗәгатьләргә кул куя;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне башкара;

5.9. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

рәсми төстә булмаган вакытта, Иҗтимагый совет рәисе функцияләрен башкара;

Иҗтимагый совет утырышларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзи һәм аны Иҗтимагый совет рәисенә раслауга тапшыра:

Иҗтимагый совет рәисенең поручениесе буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне башкара.

5.10. Иҗтимагый советның җаваплы секретаре:

утырышларга материаллар һәм карарлар проектларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый советны үткәрү урыны һәм вакыты, көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмати-белешмә материаллары белән тәэмин итә;

Иҗтимагый совет белән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең оештыру ягыннан үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген документаль-техник яктан тәэмин итүне хәл кыла;

Иҗтимагый совет утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән караларның үтәлешенә контрольлекне хәл кыла;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзүдә катнаша;

5.11. Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет утырышларында тыңлауга һәм фикер алышуга мәсьәләләр әзерләү өчен эш, эксперт төркемнәренә һәм башка эш органнарына берләшергә, материаллар әзерләүгә, Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килештереп, Иҗтимагый совет составына кермәүче белгечләрне җәлеп итәргә мөмкин.

5.12. Иҗтимагый совет үзенең эшендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларының катнашуын тәэмин итә.

5.13. Иҗтимагый советның карап тикшерүенә кертелә торган материаллар Иҗтимагый совет рәисенә Иҗтимагый совет утырышының (материалларны карап тикшерү күздә тотылган утырыш) билгеләнгән датасына кадәр ун календарь көненнән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш. Материалларны соңрак срокта тапшыру Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары белән килештерелә.

5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең оештыру-техник ягын Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тәэмин итә.

5.15. Иҗтимагый совет рәисе карары белән Иҗтимагый совет утырышына, карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматлар һәм бәяләмәләр тапшыру өчен, башкарма органнар, коммерциясез оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре һәм экспертлар җәлеп ителергә мөмкин. Иҗтимагый совет әгъзалары булып тормаучы массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет утырышларында Иҗтимагый совет рәисе чакыруы буенча катнашырга мөмкин.

Татарстан Республикасының Этил спирты,
алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм
сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин
итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау
буенча дәүләт инспекциясенең
19.04.2018 ел,
№ 12-07/57 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе каршындагы Иҗтимагый советны оештыру**
**ТӘРТИБЕ**

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе каршындагы Иҗтимагый советны (алга таба – Иҗтимагый совет) формалаштыру процедурасын һәм Иҗтимагы совет әгъзаларына карата таләпләрне билгели.
2. Иҗтимагый совет Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы советы тәкъдиме белән яки үз инициативасы буенча оештырыла.
3. Иҗтимагый совет Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә ихтыярый нигездә 14 кешедән оештырыла.
4. Иҗтимагый совет составына Россия Федерациясе гражданнары, шул исәптән иҗтимагый оешмалар һәм социаль юнәлешле башка коммерциясез оешмалар вәкилләре керергә мөмкин. Шул ук вакытта, Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләрне тикшерү өчен кирәкле булган, бу өлкәдәге тиешле белемгә, эш тәҗрибәсенә ия булуны кертеп, аларның һөнәри сыйфатлары исәпкә алына.

Иҗтимагый совет составына элегрәк Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән затлар, Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан биштән бер өлешеннән артмаган санда, керергә мөмкин.

**5.** Иҗтимагый совет әгъзалары була алмый:

Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар;

суд карары нигезендә эшкә сәләтсез дип танылган затлар;

хөкем карарына тартылган яки үзләреннән хөкем чарасы алынмаган затлар;

“Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында” 04 апрель, 2005 ел, № 32-ФЗ Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары булып тора алмаган башка затлар.

**6**. Иҗтимагый советның персональ составы Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән раслана.

**7.** Иҗтимагый совет составы булдырылган очракта Татарстан Республикасы Иҗтимагый советы тәкъдиме белән Иҗтимагый совет составы әлеге тәкъдим кергәннән соң 2 ай эчендә раслана.

Административ һәм суд практикасы
бүлеге
начальнигы урынбасары _______________________________/И.И. Җамалетдинов/_________

Кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы
көрәш бүлеге начальнигы ___________________________/Л.П. Василина/____________